Бүгенге санда:



**Авыл хуҗалыгы кышка әзерләнә.** 3 бит


# Дуслык

Дружба

Нурлат шәһәре һәм Нурлат районы газетасы

1931 елның 9 июленнән бирле чыга

Җомга 21 август 2015 ел

№ 61 (10590)


**22 августка һава торышы:** болытлы һава, җил төньяк-көнбатыштан, 3-4 м/с; температура көндез +22°С, төнлә +16°С

ХӘБӘРЛӘРЕГЕЗНЕ КӨТӘБЕЗ

Телефоннар: 2-36-13, 2-36-20.

## *Абзац-информ*

### НУРЛАТТА ВИЦЕ-ПРЕМЬЕР БУЛДЫ

Сишәмбе көнне Татарстан Премьер-министры урынбасары Васыйл Шәйхразиев районга эш визиты барышында Нурлат муниципаль районы территориясендә алкоголь һәм спиртлы продукция әйләнеше өлкәсендәге вәзгыятькә контрольлек итү Советының күчмә утырышында катнашты. Моннан тыш, ул Халыклар Дуслыгы йортындагы көндәлек тормыш белән танышты, кайбер кибетләрдәге ассортимент белән дә кызыксынды.

### РОССИЯ ӘЛӘМЕ КӨНЕ

22 августта Россиянең Дәүләт әләме көне билгеләп үтелә. Традиция буенча, бу көнне шәһәр һәм районда төрле чаралар уздырыла. Мисал өчен, бүген 15.00дә мәйданда үзәк китапханә "Әдәби ишегалды" чарасы үткәрәчәк.

### ЭШЛӘҮЧЕ ПЕНСИОНЕРЛАР ӨЧЕН

Августта районның 2803 пенсионеры арттырылган пенсия алачак. Эшләүче пенсионерларның иминият пенсияләре күләменә пенсия фонды идарәсендә еллык корректировкалау үткәрделәр. Арту уртача 134 сум тәшкил итә. Корректировкалау гариза бирмичә генә ясала. Иминият пенсияләрен гаризасыз корректировкалауга эш бирүчеләре 2014 елда иминият кертемнәре түләп барган картлык һәм инвалидлык буенча иминият пенсияләре алучылар хокуклы.

# Җиңү паркы да булачак



Автор фотосы

"ДУСЛЫК" ПАРКЫ ТР ВИЦЕ-ПРЕМЬЕРЫ ВАСЫЙЛ ШӘЙХРАЗИЕВТА УҢАЙ ТӘЭСИР КАЛДЫРДЫ

**Татарстанда быел Рөстәм Миннеханов инициативасы белән игълан ителгән Парклар һәм скверлар елы кысаларында пәйда булырга тиешле 143 заманча ял зоналарының 5се – Нурлатта.**

Республика бюджетыннан 1 миллиард сум бүлеп бирелгән республика президент программасын гамәлгә ашыру Татарстан лидерының һәрдаим күз угында тора. Аның кушуы буенча, барлык проектлар да районнар халкы белән фикер алышу узды һәм инде тормышка ашырыла. Мисал өчен, 14 августта Рөстәм Миннеханов Түбән Камада яңартылган парк һәм Габдулла Тукай исемендәге китапханәне ачты. "Парклар һәм скверлар" республика президент программасы безнең шәһәргә дә ял итү өчен заманча мәйданчыклар бүләк итте. Нурлатта паркларны үстерү юнәлешен шикәрчеләр бистәсендәге "Дуслык" скверыннан башладылар. Аннан соң ук халык күз алдында "Дуслык"ның янәшәсендә үк урын алган Владимир Медведский исемендәге сквер пәйда булды. Бүген алар, кече архитектур формалар белән бизәлгән үзәк парк кебек үк, иң популяр ял урыннарына әверелделәр. Бирегә шәһәр генә түгел, ә районның да төрле почмакларыннан киләләр. Ә бу көннәрдә Сәлимҗанов урамындагы скверны реконструкцияләү тулы көченә бара. Ял зоналарын киңәйтү Парклар һәм скверлар елы белән генә чикләнмәячәк. Нурлатта яңа Җиңү паркын төзү 2016-2017 елларда дәвам итәчәк.

– Бу паркны Көньяк-Көнбатыш микрорайонда төземәкче булабыз. Аның территориясе ике гектарлар тәшкил итәчәк, димәк, эш күләме дә зур булачак. Проект буенча зур парковка, ял зонасы, скейтмәйданчык планлаштырылган, – ди район башкарма комитетының архитектура һәм шәһәр төзелеше бүлеге начальнигы Наталья Крайнова.

Бу җәйдә шәһәргә гүзәл скверлар төзеп биргән "СтройГранд" подрядчы компаниясенең тәҗрибәсенә караганда, яңа паркны да озак көтәргә туры килмәстер. Шәһәрдәге ял зоналарында башкарылган эшләрнең масштаблылыгына һәм сыйфатына шул көннәрдә Татарстан Премьер-министры урынбасары Васыйл Шәйхразиев та бәя бирде. Сишәмбе көнне ул эш визиты белән Нурлатта булып китте. Район башлыгы Равил Кузюров озатуында Васыйл Габделгаязович В.Медведский исемендәге һәм "Дуслык" скверларында, үзәк паркта булды. Нурлатлыларның табигый зоналарга янәшәдә үк яшәү мөмкинлекләре булуына ул да сөенде. Татарстан вице-премьеры парк һәм скверларның керү капкаларына да уңай бәя бирде.

– Алар стандарт булырга тиеш, әгәр дә кергән җайда тәртип булмаса, алга үтеп торасы да юк, – диде Васыйл Шәйхразиев.

Маргарита **ЛИТТА**

АКТУАЛЬ

# Терлек асрауны тыймаячаклар

**Россиядә шәхси ярдәмче хуҗалыкларда терлекләр һәм кош-корт санына чикләүләр кертәчәкләр икән, дигән хәбәр халык арасында шактый бәхәсләр тудырырга өлгерде.**

Әмма бу уңайдан ТР Дәүләт Советының экология, табигатьтән файдалану, агросәнәгать һәм азык-төлек сәясәте буенча комитеты рәисе Таһир Һадиев: "Шәхси ярдәмче хуҗалыклар – безнең терәгебез. Безнең республикада терлекләрнең баш санын регламентлау турындагы сорау бөтенләй тормый. Киресенчә, республика җитәкчелеге шәхси ярдәмче хуҗалыкларда баш санын үрчетү, аларга дәүләт ярдәмен арттыру яклы", - дип белдерде.

Бу уңайдан нурлатлыларның да фикерләрен белештек.

**Миләүшә Фәтхетдинова, район авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе консультанты:**

– Безнең районда шәхси ярдәмче хуҗалыкларда 10 меңнән артыграк мөгезле эре терлек асрала, шуларның 4 меңнән артыграгы – савым сыерлар. Аларны асраучыларга дәүләттән ярдәм чаралары каралган. Мәсәлән, быел савым сыерларга азык алуга тотылган чыгымнарның бер өлешен каплауга һәр башка 3әр мең (узган елда 2шәр мең иде), савым кәҗәләргә 1әр мең сум акча бүлеп биреләчәк. Шәхси хуҗалыклар өчен ташламалы кредитлар да гамәлдә, таналар сатып алуга, терлекчелек биналары төзүнең бер өлешен каплауга 200әр мең сум күләмендә дәүләт ярдәме алу мөмкинлеге дә бар. Шәхси ярдәмче хуҗалыкларны үстерергә кирәк дип саныйм, нәкъ менә алар нигезендә районда 40тан артыграк гаилә фермасы барлыкка килде һәм уңышлы эшләп килә бит.

**Владимир Федоров, Илюткино авылы:**

– Без бүгенге көндә 10 баш сыер асрыйбыз, бу безнең гаиләгә көндәлек табыш биреп тора. Гомумән, авылда башка бернинди керемнәре булмыйча, терлек асрау хисабына яшәүчеләр шактый, хәтта пенсионерлар да сыер тотарга тырыша. Кеше тырыша, эшли икән, нигә аны чикләргә, ди? Киресенчә, ярдәм чараларын арттырырга гына кирәктер, минемчә. Мәсәлән, сөтне сатып алу бәяләре бүген 11-13 сум гына. Күпме хезмәт куеп җитештерелгән продукцияне кыйммәткәрәк сатасы килә.

**Галина Кульметьева, Елаур авыл җирлеге башлыгы:**

–Чикләүләр хуҗалыкларында меңәр баш терлек асрау белән шөгыльләнүчеләр булган төбәкләр өчен кирәктер, бәлки. Бездә шәхси хуҗалыклар бик зур түгел, нигездә 8-9ар баш терлек асрыйлар. Терлек асрау – авыл кешесе өчен өстәмә керем чыганагы һәм халыкның яшәү шартларын яхшыртуга хезмәт итә. Ә халык яхшы яшәсә – авыл да үсә, дигән сүз. Шуңа да чикләүләр кертүгә каршы мин: авыл кешесе терлек асрады һәм асрарга тиеш тә.

**Шул арада массакүләм-мәгълүмат чараларында Россия авыл хуҗалыгы министрлыгы комментарие да басылып чыкты. Аннан күренгәнчә, чикләүләр бөтен ил өчен бер булмаячак, аларны кертү-кертмәү хокукын төбәкләрнең үзләренә бирергә җыеналар.**

Лилия **МӨБАРӘКШИНА**

# ВӘЗГЫЯТЬ

## Сайлау алды агитациясе

**Материаллар автор эшкәртүендә тәкъдим ителә. Аларның газета битләрендә урнашуы басма мәйданны бүлү буенча җирәбә нәтиҗәләренә туры килә**


# 13 нче сентябрьдә президентлыкка "Гадел Россия" кандидатын сайла!

## Рушания Бильгильдеева - безнең кандидат!



Рушания Ахатовнаны күз алдына китерсәк, аның турында бары тик уңай фикерләр, уйлар гына туа. Ул – үрнәк алырдай шәхес, назлы әни, тугры хатын һәм әти-әнисе турында кайгыртучы кыз бала да әле. Аның җилкәсе артында гади генә тормыш юлы түгел: канатлары сынган, күңелләре төшкән, ләкин шул ук вакытта үзендә көч табып эшне яңадан башлаган вакытлары да күп булган аның. Рушания Бильгильдеева үзенең 15 ел гомерен укытучы профессиясенә багышлаган кеше. Һәм ул белем бирү өлкәсендәге проблемалар белән бик яхшы таныш. Ул һәрвакыт намуслы, гадел, тугры булуы белән башкалардан аерылып тора.

Шактый елын укытучы һөнәренә багышлаган, тарих һәм җәмгыять белеме дәресләрен алып барган укытучы буларак, ул укучыларның нинди проблемалар белән яшәвен, бердәм дәүләт имтиханнарын ничек авыр кичерүләрен ишетеп кенә түгел, ә үз күзләре белән күреп кичергән кеше.

Казан мәктәбендә иң беренчеләрдән булып куркынычсызлык кагыйдәләре буенча дәрес бирүче дә, ике ел дәвамында "Олимп" балалар үзәген булдыру өчен, ташландык балалар бакчасы биналарын торгызу буенча көрәш алып барган кеше дә Рушания Бильгильдеева булды.

2008 елда Рушания Ахатовна "Гадел Россия " партиясенә кереп иҗтимагый-сәяси эш белән бергә кешеләргә ярдәм итеп эшли башлады. 7 ел дәвамында үзенең коллегалары ярдәме белән ул намуссыз коммуналь хезмәткәрләргә каршы көрәш алып бара, "Хатын-кызлар демократик берләшмәсе" җитәкчесе буларак "Сугыш елы балалары" ("Дети войны") статусын законлаштырырга таләп итә. Бу эшләрдән кала Рушания Бильгильдеева «Россия бакчачылары» («Садоводы России») оешмасын, Татарстан кулланучылар хокукын яклау буенча «Гадел ЖКХ» («Справедливое ЖКХ), шулай ук "Гадел Россия "партиясенең халык хокукларын яклау үзәге буенча да җитәкче булып тора. Эштә көчле, таләпчән булса, өйдә ул кайгыртучан әни һәм тугры хатын булып кала бирүе аның өчен иң беренче чиратта гаиләнең имин, тыныч булуында чагыла.

Бүген ул "Гадел Россия" партиясенең Татарстан бүлеге лидеры, сөйкемле хатын-кыз, үрнәк алырдай шәхес, гаилә учагын саклаучы назлы әни һәм бар өлкәдә дә өлгерүче үз эшенең остасы булып кала бирә. Менә ни өчен Рушания Бильгильдеева безнең кандидат!

"Гадел Россия" партиясе сәяси программасының үзәгенә түбәндәге программаларны кертте:
- " Сугыш елы балалары" статусын законлаштыру;
- Балаларның фикерләрен, кызыксынуларын исәпкә алып, әни булган кешеләрнең мәнфәгатьләрен кайгырту;
- Торак-коммуналь хуҗалыгы буенча эшләр алып барган оешмаларга тикшерүләр уздыру.

**13 сентябрь көнне 1нче номерлы кандидат өчен тавышыңны бир!**

ТР Сайлау кодексының 62нче маддәсе 12нче пункты нигезендә бушлай бастырыла. Материал теркәлгән кандидат Бильгильдеева Рушания Ахатовна тарафыннан тапшырылды.


АКЦИЯ

## Мәктәпкә бергәләп җыеналар

**1 августтан Татарстанда "Мәктәпкә җыенырга булыш!" хәйрия акциясе бара.**

Аз керемле һәм күп балалы гаиләләрдәге, инвалид балаларга ярдәм йөзеннән оештырылучы бу игелекле гамәл республикада 2007 елда башланып киткән иде. Хәйрия акциясе быел Нурлатта 134 балага шатлык бүләк итәчәк. Шуларның 102се – беренче сыйныф укучылары.

– Районда "Мәктәпкә җыенырга булыш!" акциясе дәвам итә, – ди район башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Әлфия Галәветдинова. – Бүгенге көнгә 20дән артык җитәкче ярдәм күрсәтте инде.

"ТНП-Зүзәйнефть" җәмгыяте җитәкчелеге әлеге хәйрия акциясе барышында 405 мең сумга балаларны киендерсә, "АгроИнвест" идарәче компаниясенең генераль директоры Рәис Сөләйманов 100 мең сумга 30 баланы мәктәпкә әзерләгән. "Нурлатнефть" НГДУсы җитәкчелеге быел да акциядә актив катнашкан. Акциядә районыбыз мөхтәсибәте дә катнашырга теләк белдерде. Дин әһелләре 40 авылда 1әр укучыны мәктәпкә киендерәчәк. Гомумән, районның барлык оешма-предприятие җитәкчеләре 1-4әр баланы киендерергә булган.

Шул көннәрдә генә район башкарма комитеты җитәкчесе Әсхәт Габдуллин ике баланы мәктәпкә җыйды. Узган ел ул Украинадан кайтучылар гаиләсенә ярдәм иткән иде.

– Ярдәм итә алам икән, бу минем өчен сөенеч кенә. Алинә белән Эльвира иң мөһиме исән булып, яхшы билгеләргә генә укысыннар һәм әниләрен сөендереп торсыннар, – диде Әсхәт Касыймович кызларга уңышлар теләп.

Нурлаттан ялгызы ике бала үстерүче Венера Танких әлеге хәйрия акциясе турында быел гына белгән икән.

– Безгә зур ярдәм булды бу, – ди Венера. – Быел зур кызым Алинә – 3нче, ә төпчегем Эльвира 1нче сыйныфка бара.

Бүләкләргә кызлар да бик сөенделәр. "Хәзер без мәктәпкә тулысынча әзер", – диделәр алар җитәкче абыйларына рәхмәт әйтеп.

"Мәктәпкә җыенырга булыш!" акциясе 25 августка кадәр дәвам итә. 1 сентябрь алдыннан балаларга мәктәп кирәк-яраклары бүләк итәргә теләүчеләргә игелекле гамәлгә кушылырга соң түгел әле.

**Зилия ӘКСАНОВА**




Автор фотосы

ӘСХӘТ ГАБДУЛЛИН АЛИНӘ ҺӘМ ЭЛЬВИРА БЕЛӘН

АВЫЛ ХУҖАЛЫГЫ

# Кышка – тыныч күңел белән

“НУРЛАТ СӨТЕ” ХУҖАЛЫГЫНДА КЫШЛАТУ ЧОРЫНА ӘЗЕРЛЕК БЕРНИЧӘ ФРОНТТА АКТИВ БАРА.



АНАТОЛИЙ ЮРКИН ЕЛ САЕН БӨРТЕК ЯНЬЧЕЛДЕРҮДӘ КАТНАША.

**Хуҗалык басуларында икенче катка печән чаптыралар, басуларда салам әзерлиләр, ә ындыр табагында бөртекне яньчелдереп җиңсәләргә тутыралар...**

## АЗЫККА АПТЫРАМАЯЧАКЛАР

Терлекләр саны 6000ләп булган хуҗалыкта малларга кышка җитәрлек азык әзерләп калу – әнә шулай җәй дәвамында көн кадагындагы мәсьәлә. Өстәвенә, быел бөтен республика буенча хуҗалыклар җәйгә азык запасын тулысынча диярлек бетереп чыктылар.

– Узган елның шул чорында бер баш шартлы терлеккә 17,6 центнер әзерләгән булсак, быел 18,5 берәмлек азык әзерләдек. Инде бүгенге көнгә 4000 тонналап печәнебез, 18 мең тоннадан артыграк сенаж, 1540 тонналап саламыбыз бар, - ди хуҗалык җитәкчесе Вәзир Сәгыйров. – Азык әзерләү әле дәвам итә. Кукуруз кырлары да мул уңыш вәгъдә итә, тиздән аларны силоска сала башлаячакбыз. “Нурлат сөте”ндә моннан берничә ел элек районда беренчеләрдән булып бөртекне кышка яньчелдереп әзерләүгә дә керешкәннәр иде. Быел да ындыр табагында тугызынчы җиңсә тулып килә инде.

– Һәр җиңсәдә 100 тоннадан артыграк консервланган бөртек саклана. Арпа, бодай, арыш, арыш-арпа катнашмасыннан җиңсәләр тутырылды, - ди участок начальнигы Александр Бажанов.

Бөртекне яньчелдереп әзерләү – отышлы юл, дип саныйлар хуҗалыкта. Моның өчен бары махсус яньчелдергеч җайланманың гына булуы кирәк. Әнә, ындыр табагына басудан туры кайтарылган игеннәрне яньчелдереп әзерләү белән нибары ике кеше – Анатолий Юркин белән Николай Яковлев мәшгуль.

– Яньчелдереп әзерләнгән бөртекне терлек организмы күпкә җиңелрәк үзләштерә, ул витаминнарга да, файдалы матдәләргә дә бай. Кыш дәвамында без яньчелдерелгән бөртектән терлекләрне симертүдә дә, савымны арттыруда да зур файда күрәбез, - ди хуҗалык җитәкчесе.

## ФЕРМАЛАРНЫ РЕМОНТЛАРГА ПРОГРАММА БУЛЫША

Хуҗалык терлекләре әле җәйләүләрдә булса да, инде сентябрь башыннан яңадан фермаларга күченә башлаячак. Һәм, бу вакытка кадәр барлык терлекчелек биналарын да тулысынча ремонтлап һәм чистартып бетерергә кирәк. “Нурлат сөте”нең һәр бүлекчәсендә фермалар саны дистәгә якын, димәк, эш күләме дә шактый зур. Әнә, Иске Чаллы бүлекчәсендә генә дә 8 фермалары урнашкан, 1860лап баш терлек асрала. Бу көннәрдә биредә инде ремонт эшләрен төгәлләп киләләр. Анатолий Марков, Семен Демидов, Иван Мамонтовтан торган ремонт бригадасы фермаларның берсендә керү юлын ремонтлыйлар. Бүлекчәнең терлекчелек фермаларын ремонтлауны башыннан азагына кадәр шул бригада башкарып чыккан икән – үзләренә ташчы да, эретеп-ябыштыручы да, балта остасы да булырга туры килгән. Бары юу, чистарту эшләрендә генә сыер савучылар ярдәм иткән.



АНАТОЛИЙ МАРКОВ БЕЛӘН СЕМЕН ДЕМИДОВ УРТА ЧАЛЛЫ ФЕРМАСЫНДА СОҢГЫ РЕМОНТ ЭШЛӘРЕН БАШКАРАЛАР.

– Ремонтка әле җәй башында ук керешкән идек. Эшләр бетеп бара инде, - диләр ремонтчылар. Ә эш нәтиҗәләре күз алдында – фермалар чип-чиста итеп агартылган, транспортерлар тирестән чистартылып, ремонтланган, сөтүткәргечләр ачык төсләр белән буяп куелган, ишек-тәрәзәләр дә көлеп тора... Кыскасы, инде бүгеннән сөтлебикәләрне кайтарырга була.


– Иң беренче итеп сентябрь башында бозаулату бүлеген күчерәчәкбез, Анда быел иске идәннәрне сүтеп, яңаларын тездек, - ди бүлекчә зоотехнигы Рамил Сиραҗетдинов. – Аннан акрынлап башка терлекләргә чират җитәчәк.

– Бүгенге көндә Югары Нурлат, Зүзәй, Сәләнгеш бүлекчәләрендә һәм биредә 4 бригада ремонт белән мәшгуль. Быел хуҗалыкта ике сыер фермасына ремонтны республика программасы буенча ясыйбыз. Әлеге программа кысаларында ремонт эшләренә киткән чыгымнарның өчтән бер өлеше республика бюджетыннан каплана. Программа терлекчелек биналарын ремонтлауда яхшы ук ярдәм булып тора, – ди Вәзир Сәлимович.

Әнә шулай, “Нурлат сөте”ндә фермаларын ремонтларга да, азык әзерләргә дә өлгерәләр. Ә кышлату имин һәм проблемаларсыз үтсен өчен иң беренче чиратта әзерлекнең яхшы булуы кирәк тә.

Лилия МӨБАРӘКШИНА, автор фотолары

### Район хуҗалыкларында урып-җыю эшләренең барышы, планга карата процентларда




**Бу атнада торган яңгырлы һава торышы урак барышына бераз тоткарлык ясаса да, хуҗалыкларда һәр аяз көнне оптималь файдаланып эшләргә тырышалар. Кичәге көнгә 28675 гектардан игеннәр суктырылган, 59 мең тоннадан артыграк иген җыеп алынган, бер гектарга уртача уңыш 20,4 центнер тәшкил итә.**

БЕР УЧ ХӘБӘР

## ТӘҖРИБӘ УРТАКЛАШТЫЛАР

**Чәршәмбе көнне Баулы районының “Ак калфак” оешмасы һәм Бөтендөнья Татар конгрессының Баулы җирле бүлекчәсе вәкилләре Нурлатта кунакта булды.**

– Сәфәрне Нурлат белән танышу максатыннан оештырдык, – ди Баулы районының “Ак калфак” хатын-кызлар оешмасы җитәкчесе Рәзинә Шараева. – Безнең теләкне Нурлаттагы коллегаларыбыз бик теләп кабул итте. Рәхмәт аларга. Нурлатны без әле якташыбыз, хәзер авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры урынбасары Ришат Хәбипов эшләгән заманнардан бик яхшы беләбез. Биредәге халыкның тарихы һәм эше күпләргә үрнәк булырлык. Нурлатта 60 меңләп кеше яшәсә, бездә 38 мең кеше. Нурлатның чишмәләре, музейлары, парклары һәм Халыклар дуслыгы йорты безне кызыксындыра. Аннан “Ак калфак” оешмасы эше белән дә якыннан танышасыбыз килә.

Зилия ӘКСАНОВА

## УКУ ЕЛЫ АЛДЫННАН – ЗУР ӨМӘ

**Знче мәктәп коллективы “Будет чисто” республика яшьләр хәрәкәте экологик проектында актив катнаша.**

Укытучылар хәрәкәтнең сайтында теркәлеп, ял көннәрендә укучылар һәм волонтерлар белән берлектә мәктәп территориясендә һәм янәшәдә урнашкан спорт мәйданчыклары, стадионда зур өмә үткәрделәр. Уртак хезмәтнең нәтиҗәлелеген шикәрчеләр микрорайонында яшәүчеләр дә билгеләп үттеләр. Пенсионер Фаина Крайнова, үзе дә актив яшәү рәвеше алып баручы кеше буларак, мәктәп коллективына олы рәхмәтләрен белдерде.

– Тирә-якта тәртип һәм чисталык булса, дөнья да игелеклерәк һәм яктырак була. Безгә бары чит хезмәтне кадерләргә һәм үз артыбыздан җыештырып барырга тырышырга гына кирәк, - ди ул укучылар һәм укытучыларның хезмәте бушка булмасын иде, дип теләп.

Бу экологик акция Знче мәктәпнең игелекле эшләре арасында соңгысы түгел. Алар Медведский һәм “Дуслык” скверларына шефлык итүне да үз өсләренә алганнар.

Маргарита ЛИТТА

## ХАЛИСӘ БАРЫСЫН ДА УЗДЫ

**“Казан” халыкара ипподромындагы чираттагы чабыш көннәрендә Нурлат атлары янә призлы урыннар алуга ирештеләр.**

Мисал өчен, 22нче чабыш көнендә “Нурлат” ат заводының Ханна туры биясе үз ишләре арасында икенче килде. Мастер-жокей Алхаз Каппушев иярләгән аргамак Татарстанда туган 3 яшьлек һәм аннан да өлкәнрәк бияләр өчен уйнатылган 1800 метрлы дистанциядә көч сынашты.

23нче чабыш көнендә шул ук ат заводының Халисә туры биясе (җайдагы Николай Ухванов) Татарстанда туган 3 яшьлек һәм аннан да өлкәнрәк чиста токымлы чабышкылар арасында республиканың Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы призына уздырылган 2000 метрлы дистанциядә катнашты һәм беренче урынны яулады. Шул ук чабышта “Нурлат” ат заводының Алхаз Каппушев тезгенләгән Алерт җирән айгыры өченче килде. Бу көнне “Ягуар” спорт клубы аргамаклары да матур күрсәткечләргә ирештеләр. Мәсәлән, аларның Голден-Каскад туры айгыры (җайдагы Алхаз Каппушев) 4 яшьлек һәм аннан да өлкәнрәк атлар арасында 1000 метрлы дистанциядә үткәрелгән “Сабантуй-2015” призына чабышта II урынны алды.

Илназ МӨБАРӘКШИН

ЯШӘЕШ

БЕЗНЕҢ ТАРИХ



НУРЛАТ ДЕЛЕГАЦИЯСЕ

# “Бөек Болгар”: тарих белән очрашу

**14-16 августта узган “Бөек Болгар” тарихи фестиваленең атмосферасы ерактан ук сизелә иде инде.**

Күптән түгел генә ремонтланган юл, гадәти көннәрдә буш булса да, бу юлы экскурсия автобуслары, шәхси машиналар белән тулды, хәтта готик язулы һәм рыцарь тамгалары сугылган гадәти булмаган транспортны да күрергә була иде. Боларының турнирларга атлар алып килүе икән.

Хәер, Болгар тарихи-архитектур музей-тыюлыгы үзе дә бу көннәрдә урта гасырлар халәтенә чумды. Безгә билгеле булган мәйдан сүзе бирегә ристалище (ярыш мәйданы) белән алышынды. Төп вакыйгалар нәкъ шунда барды да. Көндез бирегә рыцарь сугышлары үтте, ә кичен, волынка һәм башка тарихи музыка коралларының моңы астында барысы да файер-тамаша күзәтте. Тулысынча Урта гасырдагы Русь һәм Алтын Урда чоры тарихына чуму халәте хөкем сөрде. Тирәякта тарихи киемнәрдәге кешеләр. Гадәти киемдә килүчеләр мондый киемнәрне биредән үк ала алды.

Безне ишек төбеннән үк балалар мәйданчыгы каршы алды. Анысы да тарихи рухта корылган иде. Озын сарафан кигән кызлар балалар белән борынгы рус уеннарын уйнадылар. Печәннән әмәлләгән лабиринт яныннан да балалар тыныч кына уза алмады. Шунда ук бию мәйданчыгы, бирегә теләкләре булганнар борынгы биюләрне өйрәнә алды. Кыскасы, 14-15 гасырда модада ни булган – бирегә шуларны күрергә мөмкин иде. Бирегә гаиләнең һәр әгъзасы күңеленә хуш килерлек шөгыль таба алды. Нурлаттан килүчеләрнең шактые осталар шәһәрчегендә төрле һөнәрләргә өйрәнүне хуп күрде. Мисал өчен, Нурлаттан Анна Челышевага ире үз кулы белән тәңкә чүкеп биргән икән. “Кызганыч, бүген үк кайтып та китәсе була, бик тәкаласы килә монда”, – ди ул.

Мәдәният бүлеге хезмәткәрләре, Кама аръягы һәм Нурлат шәһәре тарихы музее вәкилләре дә фестиваль атмосферасыннан таң калуларын яшермәделәр. Фестиваль кунаклары тере тарих кебек кабатланмас күренеш белән таныштылар, Урта гасырлар чорына экскурсиядән онытылмаслык тәэсирләр алдылар.

Бу чараның төп өлеше рус сугышчыларының, күчмә халыклар, укчылар, Европа рыцарьларының сугышлары, ат турнирлары һәм массакүләм сугышлар, ягъни бугуртлар булды, әлбәттә. Төркемебезнең ир-атларын көрәш мәйданыннан аерып булырлык түгел иде. Ә хатын-кызларга, әлбәттә, күңел ачуларга таба юл тотасы калды. Чүлмәкче һәм тимерче эшләре, тимердән кою, балчыктан эшләнмәләр әвәләү, күн мозаикасы, күнгә яндырып сурәтләр төшерү, чыбыктан үрү, тукучылык, варганда уйнау, тимбарларда сугышу – теләгәнең сайла гына. Моннан тыш, күп төрле интерактив мәйданчыклар, тарихи мастер-класслар, сувенир сату кибетләре эшләде. Төшке ашка исә гадәти сабантуй шашлыкларыннан тыш, Урта гасыр ризыкларын да тәкъдим иттеләр.

Без ат чабышларын да хозур кыла алдык. Шулай ук рыцарьлар тамашасы да бик тәэсирле үтте. Шунысын да әйтик, аларның кием-кораллары 25 килограмм икән!

Бирегә тарихи реконструкцияләнгән дистәләгән Россия клублары җыелды. Хәтта Израиль вәкилләре дә бар иде, монысы фестивальгә халыкара статус бирде. Фестивальнең шимбә киче күпләр өчен традициягә әверелде, барысы да түземсезлек белән тарихи юнәлештәге төркемнәрнең чыгышларын, ут тамашасын көтте. Волынка, бубен, барабан тавышлары – һәм менә концерт азагына якынлаша. Барысының да игътибары сәхнәдән көрәш мәйданына күчте. Бирегә Сәмруг кош турындагы әкият файер-тамаша утлары белән сурәтләнде. Төн караңгылыгын фейерверклар чаткысы, факел утлары, оҗмах бакчасыннан бөркелүче ялкын яктыртты. Фестивальнең икенче көне әнә шулай тәмамланды.

Якшәмбе исә урта гасыр сугышларының төгәлләнү көне иде. Финал буларак төркем сугышлары үткәрелде. Баштанаяк киенгән, коралланган рыцарьлар йөзгә-йөз киләләр, соңгы метрлар калгач, адымнарын кызулатып, кылыч, калканнарын шаулатып, көндәшләре белән йөзгә-йөз бәрелешәләр. Бернинди алдан планлаштыру да юк – барысы да чын бирегә. Бу хакта без Павловодан килгән тарихи клуб рыцарьлары белән тиз генә гәпләшеп тә алдык. Алып баручы исә, зыян күрүчеләргә ярдәм итәр өчен, еш кына көрәш мәйданына медицина хезмәткәрләрен чакырырга да мәҗбүр булды.

...Беренче тапкыр килүчеләрнең шактые Болгар музей-тыюлыгының биниһая зур мөмкинлекләре булуын белеп киттеләр. Фестиваль көннәрендә бирегә килүчеләр гадәти вакыттагыдан берничә тапкырга күбрәк булды. Икенче тапкыр уздырылучы “Бөек Болгар” алга таба тагы да күбрәк туристларны җәлеп итәр дип өметләнәбез. “Яңарыш” проектыннан соң, Болгар икенче сулышын алды, яңа комплекслар калкып чыкты, һәм һәр килгән саен сокландыруын дәвам итә.

Валентина **ВАФИНА**

НЕФТЬЧЕЛӘРДӘ

## Яңа биеклек алынды




**“Татнефть” ПАОсы 15 августта яшь хезмәткәрләр арасын**
**да һөнәри осталык конкурсы уздырды.**

Һөнәри осталык конкурсы һәрвакыт актуаль булудан тыш, торга
саен популярлаша бара. Конкурс ике этаптан тора иде. Беренчес
теоретик белемнәрне тикшерү булды. Югары катлаулылыктагы сора
улар нәкъ менә турыдан-туры производство-технологик процесслар
га кагыла да. Шуңа да конкурсантларга ансат булмады, җиңүчелә
рәтенә чыгу өчен шактый төпле белемле булу кирәк иде. Икенче эта
та гамәли күнекмәләр һәм белгечләрнең бораулау эшләрен үткәр
технологиясен белүләре тикшерелде. Теоретик һәм гамәли конкур
нәтиҗәләре буенча команда баллары саналды. Нәтиҗәләр буенч
беренче урынны “Бурение” ОООсы НПБРының мастер Артем Булыги
бригадасы яулады. Призлы урыннар алган барлык катнашучылар
да дипломнар һәм кыйммәтле бүләкләр тапшырылды.

*Реклама хокукынд*

## Осталыкка сынау үтteләр




**Узган шимбә көнне “Елховнефть” НГДУсы өйрәнү полигонында “Татнефть” ПАОсы производство төркеменең яшь хезмәткәрләре арасында традицион һөнәри осталык конкурсы үтте. Ул Нефть һәм газ сәнәгате көненә багышланды.**

Нефть әзерләү сменалары арасындагы бәйгедә “Нурлатнефть” НГДУсының Сергей Рафиков җитәкчелегендәге ЦКППН командась
беренче урынны яулады.

Шулай ук рәссамнар кон
курсында “Туган ягы
Татарстан” номинациясенд
“Нурлатнефть” НГДУсыны
рәссам-бизәүчесе Рөстә
Хәйретдинов та бәхәссе
җиңүче булды.

Спортчылар да сынатмадь
“Нурлатнефть” НГДУсы җыел
ма командасы аркан тартышу
да икенче урын алды.

Марина **КОРНИЛОВ**

*Реклама хокукында*

## ЯШЬЛӘР ВЕЛОСИПЕДТА ЯРЫША

Иртәгә “Нурлатнефть” идарәсе нефтьчеләре “Татнефть” ПАОс
структур подразделениеләре һәм бүлентекле җәмгыятьләр
сервис компанияләре яшь хезмәткәрләренең велоузышынд
катнашачак. Ул “Лениногорскнефть” НГДУсының 70 еллыгын
багышлана. 20 км.лы дистанциягә узышачак команда 4 кешедә
торачак.

КӨН КАДАГЫНДА

# Текә селфи яки кеше гомере: кайсы кыйммәт?

**"Иминлек өчен" иҗтимагый оешмасы активистлары Россия Мәгариф министрлыгына мәктәпләрдә куркынычсыз селфи ясарга өйрәтүче факультативлар кертүләрен сорап мөрәҗәгать итте. Моңа исә селфи ясаганда бәхетсезлек очракларының артуы сәбәп булды.**

Август башында Мәскәү өлкәсендәге тимер юл станцияләренең берсендә 14 яшьлек кыз бала йөк поездының цистернасында тәэсирле селфи ясарга маташканда, ялгыш үткәргечкә эләгеп китә һәм 27 мең вольтлы көчәнешле ток сугуыннан урында ук һәлак була. Хәер, бу бердәнбер очрак түгел, Россия буенча селфи ясаганда имгәнүчеләр 100дән артыграк исәпләнә, үлүчеләр дә дистәгә якын. Кемдер кулында корал белән, кемдер руль артында барганда, кемдер эстакадада фотога төшкәндә һәлак булган… Әмма, нишләптер, башкаларныкыннан үзгә фоторәсем ясарга тырышып, үз тормышларын куркыныч астына куючы үсмерләр саны кимеми.

Селфи – автопортретның бер төре, кеше үз смартфонында үзен фотога төшерә. Беренче селфиларның тарихы 19нчы гасырларга ук барып тоташса да, аның киң таралыш алуы 2000нче – мобиль җайланмалар һәм аларга урнаштырылган фотоаппаратлар пәйда булган елларга туры килә. Бүгенге көндә селфи шулкадәр модага кергән, социаль челтәрләр шундый автопортретлар белән тулы. Инстаграмда селфи хэштегы буенча 305 млн. фото табарга мөмкин.

Әлбәттә, үз йөзеңне гади итеп, бүлмәңдә рәсемгә төшереп кенә берәүне дә гаҗәпләндерә алмыйсың. Шуңа да яшьләр селфины ниндидер гадәти булмаган урыннарда, экстремаль шартларда ясарга тырышалар. Социаль челтәрләргә урнаштырылган селфи никадәр күбрәк лайк җыйса, шулкадәр текә булачаксың, дип уйлый яшьләр. Нурлат яшьләреннән дә "иң текә селфиегыз нинди булды?" дип кызыксындык. Сораштыруда катнашучыларның күбесе селфины танылган, күренекле кешеләр белән ясарга яратуларын әйтте. Ял итәргә баргач, төркемләп төшәргә яратучылар да юк түгел. Илнең төрле почмакларында истәлекле биналар фонында төшәргә тырышучылар да бар. Экстремаль селфиларны яратучылар да шактый булып чыкты.

– Казанда иптәшләрем белән бергә 15 катлы йортның түбәсенә менеп селфи ясадык. Бик текә килеп чыкты, - диде бер яшь студент егет.

Нурлатта селфи өчен текә урыннар сайлаучылар да юк түгел икән. Берәү тимер юл кичүе күперенең популяр булуын әйтте.

– Шөкер, безнең станциядә куркынычсызлык кагыйдәләрен бозып селфи ясарга тырышучы яшьләр теркәлмәгән. Бәхетсезлек очракларын булдырмау максатыннан бездә даими рәвештә рейдлар үткәрелеп тора, - ди станция начальнигы урынбасары Людмила Смолина. – Балалар арасында имгәнүләрне кисәтер өчен мәктәпләрдә аңгәмәләр үткәрәбез, аларга тимер юлларда куркынычсызлык кагыйдәләрен үтәүнең мөһимлеге турында сөйлибез. Әлбәттә, алдагы очрашуларда селфиларның нинди бәхетсезлек очракларына китерүе хакында да аңлатачакбыз.

Инде бүгеннән үсмерләр фотога төшәргә ярата торган куркыныч урыннарда бу шөгыльне тыючы табличкалар урнаштырырга дигән тәкъдимнәр бар. Россия МВДсында исә әле җәй уртасында ук, селфи ясаганда яшьләрнең күпләп һәлак булуын искә алып, куркынычсыз селфи ясарга өйрәткән белешмәлекне матбугат конференциясендә тәкъдир иттеләр.

– Әлеге белешмәлектә кайда фотога төшәргә ярамавы тәфсилләп аңлатылган, бәхетсезлек очракларының мисалларына кадәр китерелгән. Аның белән Россия МВДсының сайтында танышырга мөмкин. Шөкер, Нурлатта селфи белән бәйле бәхетсезлек очраклары теркәлмәгән. Әмма селфи ясарга яратучылар күп, һәм бу фотога төшкән вакытта бар игътибарның камерага тупланган булуы белән куркыныч. Артта ни барын фотограф күрми, һәм ялгыш бер адым да бәхетсезлеккә китерергә мөмкин. Шуңа да яшьләр һәм үсмерләр арасында профилактика алып бару кирәк, һәм белешмәлекләр бу яктан хокук сакчыларына да, педагогларга да зур ярдәмлек булачак, - ди Россия МВДсының Нурлат полициясе бүлеге начальнигы урынбасары Илдус Тямаев.

Районның мәгариф учреждениеләрендә дә балаларга куркынычсыз селфи ясарга өйрәтү кирәк, дип саныйлар.

– 17 августтан Татарстанда "Балалар иминлеге " айлыгы үтә. Мәгариф учреждениеләрендә ай дәвамында балаларга куркынычсызлык кагыйдәләрен исләренә төшерәчәкбез. Әлбәттә инде, куркынычсыз селфи темасына да кагылачакбыз, - ди мәгариф бүлеге начальнигы урынбасары Эльмира Шагаева.

Әпсихологлар үсмерләр арасында селфи-бәйлелек проблемасы барлыкка килүе хакында чаң сугалар. Мәскәүдә хәтта бу уңайдан тәүлек әйләнәсе эшли торган экстрен служба да булдырылган. Психологлар яшьләр шул рәвешле үзләренә игътибар юнәлтергә тырыша, дип саный. Ә Дәүләт Думасы депутатлары бу проблемага каршы куркыныч урыннарда селфи ясаучы үсмерләрнең әти-әниләренә административ штрафлар салу юлы белән көрәшмәкче. Штраф күләмен 10 мең сумга кадәр ясарга дип тәкъдим итүчеләр дә бар... Әмма халыкны, аеруча яшьләр һәм үсмерләрне штрафлар белән куркытып кына зур файда булырмы икән? Хәлиткеч карарны кеше үзе ясарга тиеш: кеше гомере һич тә текә селфига тормый бит.

Лилия МӨБАРӘКШИНА



Фото интернет-чыганактан алынды

**ИГЪТИБАР!**

**Ә сез бу хакта ни уйлыйсыз? Фикер-тәкъдимнәрегезне безнең белән nurlat-tat.ru сайтында уртаклаша аласыз.**

ВАТАНГА ХЕЗМӘТ!

# Әти-әниләр хәрби антка йөри

**Нурлатлылар арасында уллары хезмәт узган частька хәрби ант тантанасына бару матур гадәткә кергән.**

Әнә, Ринат һәм Зөлфия Гәрәевлар да күптән түгел шундый сәфәрдә булып кайттылар.


Гәрәевларның уллары Фаил Свердловск өлкәсенең Елань шәһәрендә хәрби хезмәт уза.

– Фаилне 17 июньдә армиягә озаттык, – дип сөйли гаилә башлыгы Ринат. – 26 июльдә хәрби ант кабул итәчәкбез, дигән хәбәр алуга юлга җыена башладык. Шөкер, 1000 чакрымнан озынрак юлны исән-имин үтеп барып җиттек.

Гомумән, июнь ае Гәрәевларны яхшы ук "селкетеп" алган икән: 12 июньдә кызлары Гөлинәнең туен бәйрәм итсәләр, биш көннән уларын армиягә озату кичәсен уздырганнар. Фаил янына Гөлинә белән кияүләре Илнурны да алып барганнар. Фаил исә хәрби хезмәткә зур теләк белән киткән. Әмма армия мәктәбенә беркадәр тормыш тәҗрибәсе туплап китәсе килгән егетнең. Шуңа аграр техникум тәмамлаган, механик белгечлеге үзләштергән, шул арада машина йөртүче таныклыгы алырга да өлгергән. Һәм болар бар да файдага булган. "Әле ике айлап кына хезмәт итсәм дә, армия ошый, дөрес, берәр атна сагындырды башта, аннан күнелде, яңа дуслар да табылды", – ди яшь солдат. Нурлаттан шул ук частька хезмәт итүче Ринат исемле егет белән дә дуслашып өлгергәннәр икән. Алар бер үк казармада яшиләр дә әле.

– Шөкер, хәзер армиядәге вәзгыять яхшы якка үзгәрешкә бит. Улыбыз хезмәт узган частьта булгач, моңа тагы бер инандык. Командирлар әйбәт, яхшы каршы алдылар, хәрби ант кабул итү тантанасы да матур узды. Аннан "увольнение" бирделәр, рәхәтләнеп табигать кочагында ял иттек. Барыннан да канәгать калдык. Берүк исән-имин хезмәт итеп кайтырга язсын инде, – диләр Ринат һәм Зөлфия Гәрәевлар.

Илназ МӨБАРӘКШИН



ФАИЛ ГӘРӘЕВ ЭЛЕМТӘЧЕ БУЛЫП ХЕЗМӘТ ИТӘ

**КЫСКАЧА**

## КОРЪӘННЕ ШИГЫРЬГӘ САЛМАКЧЫ

Җирле шагыйребез Фәүзия Мөхәммәтова Коръән сүрәләре фазыйләтләрен шигъри калыпка салу белән мәшгуль. Хажия, дин кануннарын тотып яшәүче автор шул рәвешле барлык 114 сүрәнең дә асылын укучыга ачмакчы. Хәзер ул эшен тәмамлап килә инде.

– Бик саклык белән эшләргә, язганнарга каткат әйләнеп кайтырга туры килә,–ди Фәүзия ханым.–Башта үзең һәр сүрәнең асылына төшенмичә, аны шигъри юлга салып булмый бит. Нинди зур хезмәткә алынуымны торган саен тирәнрәк аңлыйм. Әмма аны ахырына җиткереп, укучы хозурына тапшыруны үзем һичшиксез башкарырга тиешле бурыч дип билгеләдем инде.

Сәкинә ХӘЙРУЛЛИНА

## ЮГАЛГАН ХАНЫМ ТАБЫЛГАН

Безнең сайт күптән түгел генә югалган бер хатын-кызны эзләү турында хәбәр бастырган иде. МВД бүлегеннән хәбәр итүләренчә, шул көннәрдә ул табылган.

Әлеге хатын-кызның кайдалыгы турындагы хәбәр полиция бүлегенә Краснодар краендагы коллегаларыннан кергән. Югалган ханым көньяк тарафка юлаучы машинага утырып киткән. Соңрак билгеле булганча, бу хатын-кыз элегрәк тә шулай югалгалый торган булган икән.

Валентина ВАФИНА

# КОТЛАУЛАР. БЕЛДЕРҮЛӘР. РЕКЛАМА

## КОТЛЫЙБЫЗ!

**Заречный поселогында** гомер кичерүче кадерлебез **Зөлфия Гыйльман кызы Галиеваны** юбилее белән ихлас котлыйбыз.

Күңеленә җыйган
яхшылыклар
Изгелекләр булып
кайтсыннар,
Туар таңнар алып килсен сиңа
Сәламәтлек, бәхет,
шатлыклар.

**Тормыш иптәше, балалары, кияве, килене, оныклары.**

## НЕДВИЖИМОСТЬ

*3-комнатная квартира, ул. Шашина. Т.: 4-37-60, 8-927-474-46-16.
*дом. Т. 8-927-462-17-01.
*дом. Т. 8-987-421-39-97.
*1-комнатная квартира (малосемейка). Т. 8-937-525-51-77.
*дом, мкр. Северный, ул. Фахрутдинова. Т.: 8-987-954-98-78, 8-917-164-80-53.
*срочно 1-комнатная квартира, ул. Гиматдинова, 480 тыс.руб. Т. 8-917-279-49-11.
*1-комнатная квартира, центр. Т. 8-937-291-31-22, Татьяна.
*дом в с. Якушкино, газ, вода, свет, участок 43 соток. Т. 8-912-757-13-80.
*дом 116,4 кв.м. с земельным участком, ул Михеева, 21-1. Цена 2600000. Т. 8-927-249-25-35.
*дом, ж/д. Т. 8-927-431-48-09.
*капитальный гараж с документами. Возле старого военкомата ул. Гиматдинова. Т. 8-919-687-03-51.
*3-комнатная квартира, мкр. Яшлек или меняется на дом. Т. 8-987-214-20-58.
***дома**, ул. Кутузова, ул. Михеева, Вишневая Поляна, Бутаиха, **2-комнатные квартиры:** ул. Заводская, ул. Кариева, **1-комнатная квартира**, ул. Советская. Т.: 8-9274-222-456, 8-937-77-40-132.
*дом, ул. Маяковского, 59-2, 60 кв.м, 1,3 млн.руб. Т. 8-937-610-48-70.
*жилой дом, мкр. ж/д, 750000 руб. Т. 8-937-610-48-70.
*жилой дом, ул. Синдрякова, 2850 тыс.руб., 150 кв.м. Т. 8-937-610-48-70.
*2-комнатная квартира, ул. Ленинградская, 1,2 млн. руб. Т. 8-937-610-48-70.
*2-комнатная квартира, 5 этаж, 50 кв.м, 820 тыс.руб. Т. 8-937-610-48-70.
*жилой дом, д. Курманаево, 120 тыс.руб. Т. 8-937-610-48-70.
*жилой дом, с. Биляр-Озеро, 120 тыс. руб. Т. 8-937-610-48-70.
*жилой дом, д. Берлик, 100 кв.м, 350 тыс.руб. Т. 8-937-610-48-70.
*3-комнатная квартира, 5 этаж, мкр. Яшлек, 60 кв.м, 1,2 млн.руб. Т. 8-937-610-48-70.
*3-комнатная квартира, 5 этаж, мкр. Яшлек, 60 кв.м, индивидуальное отопление, 1430 тыс.руб. Т. 8-937-610-48-70.
*комната в общежитии, 16 кв.м, 200 тыс.руб. Т. 8-937-610-48-70.
*1-комнатная квартира, ул. Советская, 3 этаж, 580 тыс.руб. Т. 8-937-610-48-70.
*коттедж, ул. Симбирская, 3,6 млн. руб. Т. 8-937-610-48-70.
*дом недострой, ул. Звездная, 100 кв.м, 950 тыс.руб. Т. 8-937-610-48-70.
*2-комнатная квартира, мансарда, 650 тыс.руб. Т. 8-937-610-48-70.
*2-комнатная квартира, новая, 2 этаж, 50 кв.м, 1250 тыс. руб. Т. 8-937-610-48-70.
*3-комнатная квартира, новая, 70 кв.м, 3 этаж, 1450000 руб. Т. 8-937-610-48-70.
*жилой дом, ул. Полевая, 11, 1,5 млн. руб., 80 кв.м. Т. 8-937-610-48-70.
*элитный коттедж, 6 млн.руб. Т. 8-937-610-48-70.
*недостроенный дом. Т. 8-927-462-08-10.
*3-комнатная квартира. Т. 8-927-462-08-10.
*1-комнатная квартира в мкр. Яшлек, 500 тыс.руб. Т.: 8-927-403-91-42, 8-927-245-66-78.
*1-комнатная квартира по ул. Самаренкина, 18, 2 этаж. Т. 8-927-451-94-28.
*дом, мкр. Северо-Восточный. Т. 8-927-492-36-10.
***1-комнатная квартира**, ул. Дружбы,60, 620 тыс.руб., **2-комнатная квартира**, ул. Советская, 195, 990 тыс.руб., дом, ул. Кутузова, 1550 тыс.руб., **дом новый**, ул. Юбилейная, 3600 тыс.руб., коммерческое помещение, ул. Нурлатская, 1100 тыс. руб. Т. 8-929-727-12-82, Ксения.
*участок, мкр. Новый Северный (подвальный этаж готовый). Т. 8-927-428-85-65.
*дом, 160 кв.м, центр, гараж, баня, хозпостройки. Т. 8-927-039-87-05.
*1-комнатная квартира, с/з, 500 тыс. руб. Т. 8-937-610-48-70.
*2-комнатная квартира, ул. Нефтяников, 40 кв.м, ремонт, 950 тыс.руб. Т. 8-937-610-48-70.
*жилой дом в д. Русская Менча, 100 кв.м, 1 млн.руб. Т. 8-937-610-48-70.
*2-комнатная квартира, ул. Ленинградская, 2 этаж, 45 кв.м, 1,1 млн. руб. Т. 8-937-610-48-70.
*дом. Варианты. Т. 8-919-684-40-03.
*гараж напротив здания телевидения. Т.: 2-42-17, 8-927-485-23-11.
*1-комнатная квартира, мкр. Яшлек. Т. 8-927-473-25-64.
*дом, ул. Малая, 2. Т. 8-917-390-64-01.
*дом, ул. М.Джалиля, 25. Т. 8-929-726-38-80.
*жилой дом, В.Поляна. Т. 8-917-251-39-33.

## АВТОТРАНСПОРТ

*Калина универсал, 2011г/в. Т. 8-927-247-25-28.
*«ВАЗ-21053», 2006 г/в. Т. 8-937-620-04-26.
*«ВАЗ-21110», 2000 г/в, 40 тыс. Торг уместен. Т. 8-927-451-24-97.
*«ВАЗ-21102», серебристо-золотой, 2001 г/в, музыка, сигнализация, стеклоподъемники, хорошее состояние. Т. 8-937-003-84-85.
*«ВАЗ-21114», 2012 г/в. Т. 8-937-621-63-85.
*бортовой «УАЗ-3303», в удовлетворительном состоянии, 1992 г/в, 50000 руб. Т. 8-917-263-99-32.
*«Дэу Матиз», 2012 г/в. Т. 8-937-600-49-37.
*«ВАЗ-2114», 2002 г/в. Т. 8-937-287-57-12.

## ДРУГОЕ

*сахар-2230, мука-970, магазин «Юмарт» . Т. 8-927-445-68-55.
*куры-молодки, бройлеры, несушки, утки, гуси. Т. 8-927-483-06-10. 8-917-293-27-47.
*утки, гуси, молодки, бройлеры. Доставка. Т.: 8-937-286-57-23, 8-937-621-81-57.
*доски осина, сосна, брусья 6 метров. Доставка. Т. 8-937-003-84-85.
*ПГС, песок, глина, перегной, грунт от 3 т. Т. 8-927-424-02-83.
*дрова. Т. 8-987-213-32-95.
*куры, утки, мularды. Т.: 4-35-11, 8-927-422-92-58.
*перегной, бут, грунтощебень. Т. 8-927-463-63-17.
*бычки (молодняк). Т. 8-927-870-49-62.
*бычки, молодняк. Т. 8-937-453-40-91.
*песок, ПГС от 3 тонн. Т. 8-927-244-84-71.
*ПГС, бут, песок. Т. 8-927-675-54-96.
*ПГС, бут, песок. Т. 8-987-283-18-34.
*песок, ПГС, бут, цемент, керамзит, щебень. Т. 8-937-287-45-40.
*ПГС, песок, бут. Т. 8-927-247-27-37.
*поросята. Т. 8-937-770-46-59.
*шифер, б/у (50 руб.), доски, б/у (50 руб.). Т. 8-937-525-60-85.
*дрова. Т. 8-937-003-27-27.
*поросята разного возраста, с. Елаур. Т. 4-32-77.
*гараж на санях, недорого. Т. 8-927-444-00-35.
*козлята, коляска-трансформер. Т. 8-987-189-59-20.
*декоративные обналички, деревянные окна на веранду, кровать двухспальная, шкафы офисные, кожаные кресла. Т. 8-917-891-14-90.
*новый диван + 1 кресло. Т. 8-927-454-75-33.
*банные камни. Т. 8-927-428-85-65.
*памперсы, коляска, противопролежневый матрас. Т. 8-927-040-66-24.
*корова, телята. Т. 8-937-621-83-62.
*телка стельная, черная, корова красная. Т. 8-937-294-08-00.
*кроватка, коляска. Т. 8-929-720-41-31.
*металлическая печь для бани, недорого. Т. 8-937-042-11-51.
*лодка М-2 «Казанка», с двигателем, в отличном состоянии. Т. 8-927-756-98-74.
*резина с дисками «Кама-515», 205x75, R-15; кузовные детали на «Ниву», новые. Т. 8-927-244-08-38.
*спальный гарнитур, газ.плита «Идель», оконные блоки, б/у. Т. 8-927-448-86-46. *дрова. Т. 8-927-414-61-34.
*дрова, ПГС, песок. Т. 8-937-617-11-21.
*грунт, ж/б кольца. Т. 8-927-403-51-99.
*песок строительный в мешках, доставка. Т. 8-937-599-75-10.
*тележка для САКа. Т. 8-937-599-75-10.
*корова. Т. 8-917-248-86-44.

## ТРЕБУЕТСЯ

*в ЭПУ «Нурлатгаз» слесарь по эксплуатации и ремонту газового оборудования, повар 4 разряда, слесарь КИПиА 5 разряда, электромонтер по ремонту и обслуживанию электрооборудования 5 разряда. Адрес: ул. Гиматдинова, 158. Т. 2-14-03.
*строительной организации бригада электриков и электромонтажников, оплата высокая. Т.: 2-28-78, 8-937-299-82-62, 8-917-935-05-76.
*репетитор, 3 класс. Т. 8-927-470-68-61.
*в м-н инструментов по ул. Самаренкина на постоянную работу продавец. Т.: 8-929-722-03-51, 8-937-290-95-11.
*няня. Т. 8-927-246-54-47.
*повара, пекари со стажем работы. Т. 2-32-99.
*каменщики, г.Казань, з/п 25-40 т.р. Т. 8-927-243-66-86.
*рабочие для физической работы, упаковщики (-цы). Т. 8-927-437-18-18 (звонить до 18.00).
*парикмахер. Т.: 8-937-790-76-52, 8-937-658-74-45.
*продавец (двери). Т.: 8-937-790-76-52, 8-937-658-74-45.

## РАЗНОЕ

*ремонт холодильников на дому. Т. 8-927-419-56-48.
*КРОВЛЯ И ВСЕ ВИДЫ СТРОИТЕЛЬНЫХ РАБОТ. БЫСТРО И КАЧЕСТВЕННО. Т. 8-927-422-26-33.
*ремонт холодильников. Т.: 2-71-69, 8-937-610-58-78.
*натяжные потолки. Т. 8-9270-365-365, Алексей.
*ремонт стиральных машин. Т. 8-927-468-16-31.
*сантехника (вода, канализация, отопление). Т. 8-937-526-56-86.
*ремонт пластиковых окон. Т. 8-927-249-54-24.
*установка дверей, окон, откосов. Т. 8-927-671-26-59, 8-987-189-59-02.
*кузовной ремонт. Т. 8-917-865-30-35.
*копаем, чистим колодцы, копаем траншеи, канализации. Т. 8-937-776-79-45.
*копаем, заливаем фундамент, услуги каменщика. Т. 8-937-294-65-52.
*копаем, заливаем фундамент, копаем траншеи, канализации, водопровод. Т. 8-937-589-51-73.
*ищу работу сиделки, домработницы. Т. 8-927-421-18-10.
*с 20 по 27 августа в храме Илии Пророка будут прибывать мощи блаженной Матроны Московской. Доступ к мощам будет осуществляться с 8.00 до 17.00. Каждый день в храме будут совершаться 9.00 – молебен о здравии и 11.00 – панихида об упокоении. Контактный телефон. 8(84345) 2-37-08.
*молодая девушка ищет соседку для совместного проживания в г. Самара. Т. 8-927-779-16-97.
*репетиторство 8-11 классы. Подготовка к ОГЭ и ЕГЭ по химии. Т. 8-927-672-76-36.

## КУПЛЮ

*Алгы приводлы «ВАЗ»лар, читил машиналары. Кыйммәткә. Т. 8-927-456-00-07.
*КЫЙММӘТКӘ АВТО САТЫП АЛАМ. Т. 8-937-588-36-46.
*КРС. Т. 8-927-481-30-38.
*баллоны кислородные, углекислотные. Т. 8-987-292-01-10. ООО «ГК «Втормет».
*КРС и шкуры КРС, дорого. Т. 8-927-443-05-43.
*авто в любом состоянии на авторазбор. Т. 8-927-246-51-99.
*участок. Т. 8-927-413-86-26.
*пух гусиный (мокрый, сухой), старые подушки, перины. Т. 8-987-062-55-26.
*КРС, шкуры КРС. Т. 8-927-412-29-99.
*овечью шерсть. Т. 8-937-592-37-56.
*ковер 3x4, сервант, мясорубку. Т. 8-927-447-62-99.

## СДАЮТСЯ

*в парикмахерской в аренду рабочие места. Т. 8-937-287-68-88.
*комната с хозяйкой, ул. Спортивная, 12-14 (одинокой женщине, молодым без детей), оплата 1000 руб.
*2-комнатная квартира в центре с гаражом. Т.: 8-937-774-24-88, 8-927-675-92-88.
*квартира в г. Казань. Т. 8-927-423-76-74.

## СНИМУ

*1-комнатную квартиру в мкр. Яшлек. Т. 8-927-248-39-93.
*квартиру на длительный срок. Т. 8-987-125-13-01.
*порядочная семья чистую 2-комнатную квартиру в районе 9-й школы. Т. 8-937-773-98-04.
*3-комнатную квартиру с хорошим ремонтом и мебелью (1 или 2 этаж) в г.Нурлат на 2 года. Гараж около дома приветствуется. Гарантирую предоплату за три месяца. Т. 8-927-417-23-27.
*1-комнатную квартиру на с/з. Т. 8-927-246-09-44.

## ПОТЕРИ

*утерянное удостоверение АТ 490575 выданное на имя Владимира Анатольевича Никитина, считать недействительным.

## СТОЛ НАХОДОК

*найдены документы на имя Дианы Марсовны Фаттаховой. Обращаться в отдел рекламы газеты «Дружба».





✓Оформление по ТК РФ
✓Иномарки, постоянное обновление
✓Высокий уровень зп
✓Корпоративная связь
✓Страховка
✓Ремонт в СЦ
✓При приеме обязательно наличие у водителя карты для тахографа ЕСТР

ЗВОНИТЕ: +7-962-567-36-23
ТЕЛ. В НАБЕРЕЖНЫХ ЧЕЛНАХ: +7(8552)77-82-82

*Делко. Реклама


12+ **“ТНТ-Нурлат” тәкъдим итә**

**24 АВГУСТ**
Музыкаль тапшыру, чуваш телендә.

**26 АВГУСТ**
“Нурлат хәбәрләре”,
“Татнефть” хәбәрләре.

**28 АВГУСТ**
**“Нурлат хәбәрләре”.**
**“Сиңа дигән җырым”,** музыкаль тапшыру

Программалар **19 сәгатьтә** башлана. **25, 27, 29 августта** иртәнге **7дә** кабатлап күрсәтелә.


**ООО «ПЕРСПЕКТИВА»** ПРОДАЕТ ИЛИ СДАЕТ ГОТОВЫЙ ОБЪЕКТ: «ФЕРМА ПРОИЗВОДСТВА МОЛОКА НА 24 ГОЛОВЫ КРС» ПО АДРЕСУ: Д.КУРМАНАЕВО, УЛ. ТИМУРОВСКАЯ, Д.6А.
*СУММА ДОГОВОРНАЯ.*
СПРАВКИ ПО ТЕЛ.: 2-58-21, 2-58-24, ПО АДРЕСУ: Г.НУРЛАТ, УЛ. ЗАВОДСКАЯ,1.

**ПЛАСТИКОВЫЕ ОКНА «KRAUSS»**
**С 1 января по 31 декабря 2015 г. при заказе 5 окон, 6-е в подарок***
**Деревенские окна по 2000 руб.**
**Откосы, подоконники, москитные сетки.**
**Работаем по всему Татарстану.**
**Рассрочка без % (предоставляет ИП Ахметов Ф.Ф.).**
***подробности по т.: 8-9274-000-606, 8-9272-449-000.**
**ИП Ахметов Ф.Ф.**

**ОЦМП «Классик»**
*реализует*
*ПРОФНАСТИЛ оцинкованный, окрашенный, под искуственный камень, под дерево.*
*Гладкий лист. С-8, С-10, Сс-10, СШ-10, МП-20, С-21, НС-35, НС-44.*
*Металлочерепица:*
*- «Супермонтерей»*
*- «Каскад»*
*- «Классик»*
Сайдинг металлический:
- «Корабельная доска»
- «Блок-хаус»
- «Софит»
- под дерево.
Доборные элементы, водосточная система.
Евроштакетник.
**ВСЕГДА НИЗКИЕ ЦЕНЫ!**
**Наш адрес: г.Нурлат, ул. Заводская, 1А, напротив ЖБИ**
**Т.: (884345)2-54-00, 8-9276-778-776.**

**Стоматология ООО «МЕТА-ДЕНТА»**
**- ТЕРАПИЯ** от 650 руб.
**- ОРТОПЕДИЯ-ПРОТЕЗИРОВАНИЕ**
**- УДАЛЕНИЕ.**
*При протезировании - удаление зубов бесплатно.*
**Ул. К.Маркса, 2, тел.: 2-00-92, 8-927-489-99-96; ул. Советская, 141** (бывший клуб нефтяников), **тел.: 2-23-00, 8-927-45-000-26.**
**Имеются противопоказания.**
**Необходима консультация специалиста.**
Реклама

